**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Лельвиж авыл җирлеге башлыгы карары**

**15 октябрь, 2025 ел** **№ 4**

**«Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлеге Лельвиж авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2025 елның 30 октябрендә 9 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлегенең Лельвиж авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Лельвиж авылы, Мәктәп ур., 2 адресындагы авыл клубы бинасында уздырырга.

2. 2025 елның 30 октябрендә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлегенең Лельвиж авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Лельвиж авылы, Мәктәп ур., 2 адресындагы авыл клубы бинасында уздырырга.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Лельвиж авыл җирлегенең Лельвиж авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түбәндәгеләрдән тыш:
- 1 төркем инвалидлары;
- көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлар (курсантлар);
- 80 яшькә җиткән затлар һәм аннан да өлкәнрәкләр;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлар;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары;
- махсус хәрби операциядә катнашучы контракт хезмәте хәрбиләре һәм аларның гаилә әгъзалары –
1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

**- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элементләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;**

**- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;**

**- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү;**

**- яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту;**

**- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;**

**- янгынга каршы резервуарларны (янгын сүндерү өчен кулланыла торган сулыкларны), янгын пирсларын урнаштыру, ремонтлау;**

**- һәйкәлләрне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаганнары) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү;**

**- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;**

**- тротуарлар ясау, ремонтлау;**

**- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары составына кермәгән җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау;**

**- традицион күмү урыннарын төзекләндерү, коймалар кору, ремонтлау;**

**- каты көнкүреш калдыкларын туплау мәйданчыкларын төзү, каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү;**

**- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү**

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүлү.

4. Лельвиж авыл җирлеге башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Лельвиж авыл җирлеге башлыгы: Э.Ю. Игнатьева

ОГРН 1021607753254
ИНН 1623003890